ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

21.03.2022 с. Набережные Моркваши № 8

## 2022нче елның язгы чорында Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары, Яр Буе Моркваშы авыл җирлеге Уставы нигезендә, тискәре табигать-климат шартлары барлыкка килгән чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының сәләтен киметүне булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1.1. 2022 елның 1 апреленнән 30 апреленә кадәр Яр Буе Моркваშы авыл җирлегенең барлык транспорт чарасына туры килә торган массасы 6 тоннадан артык булган (алга таба - язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап йөк белән яисә йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү 3.12 "Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү" юл билгеләрен урнаштыру юлы белән Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган өстәмә мәгълүмат (табличкалар) 8.20.1 һәм 8.20.2 "Транспорт чаралары тибы" тамгалары белән гамәлгә ашырыла.

3. Россия Эчке эшләр Министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенең ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Моркваშы авыл җирлегенең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны 2022 елның 1 апреленә кадәр, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Канаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____________И.Х.Гаязов